Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылындагы
гражданнар җыены

# КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге составына керүче Татар Баганалысы авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 19 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- вак таш салып чокырлы юлларны ремонтлау (сатып алу, китерү, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);
- урамнарны яктыртуны карап тоту (урам яктырткычларын энергияне саклаучы яктырткычларга алыштыру, килешү буенча түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 416 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 215 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 215 катнашучысы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- вак таш салып чокырлы юлларны ремонтлау (сатып алу, китерү, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);

- урамнарны яктыртуны карап тоту (урам яктырткычларын энергияне саклаучы яктырткычларга алыштыру, килешү буенча түләү).

3. Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан тыш, 1000 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- вак таш салып чокырлы юлларны ремонтлау (сатып алу, китерү, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);
- урамнарны яктыртуны карап тоту (урам яктырткычларын энергияне саклаучы яктырткычларга алыштыру, килешү буенча түләү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татар Баганалысы авыл җирлеге
башлыгы ________________ Р.Р.Җәббаров